

**- Уңышлар сезгә!**

# Өй эшен тикшерү

1)112 нче күнегү, 85 нче б. Башваткычны чишү өчен, җавапларны шакмакларга яз. Билгеләнгән урынга килеп чыккан сүз турында сөйлә.

2) Саннар кулланып, көндәлек режим турында сөйләргә.




# Чиста язу күнегүе


**6н, 100ек, 1дәм, м10нча, к3, т10, 5ек.**

***Алтын, йөзек, бердәм, мунча, көч, тун, бишек.***



# Уку мәсьәләсен кую


“Ике ялкау” әкияте


“Ике кыз” әкияте


“Өч кыз” әкияте

- Бу рәсемнәр кайсы әкиятләрдән?
- Әлеге әкиятләрнең татар теле дәресе белән нинди бәйләнеше бар?
- Бүгенге дәрескә нинди уку мәсьәләсе куярбыз?

**Егерме алтынчы ноябрь.**

**Сыйныф эше.**

**Сан сүз төркемен кабатлау.**

# Сан турында белгәннәрне искә төшерү

## Куиз-куиз-трейд

1. Укучылар кулларын күтәреп, үзләренә пар эзлиләр.
2. Бер укучы сорау бирә, икенчесе җавап бирә.
3. Җавап дөрес булса, беренче укучы иптәшен мактый, дөрес булмаса, аңа булыша.
4. Икенче укучы сорау бирә. Җавап дөрес булса, иптәшен мактый. Дөрес булмаса, аңа булыша.
5. Укучылар карточкаларын алмашалар.
6. Укучылар 1-5 нче адымнарны кабатлыйлар.



"Сора-сора-алыштыр"




# 2015 нче елда Бөек Җиңүгә 70 ел тула!



Текстны укы. Саннарны саналмышы белән язып ал.

## Сайланма диктант.

**9 нчы май – Җиңү көне. 2015 нче елда Бөек Җиңүгә 70 ел тула. Бөек Ватан сугышына Теләче төбәгеннән барлыгы 4457 кеше киткән. 3046 кеше яу кырында ятып калган.**

**Ветераннарга мәңгелек дан!**

***Тикшер:***

***9 нчы май, 2015 нче ел, 70 ел, 4457 кеше, 3046 кеше.***

# Дәреслек белән эш

**101 нче күнегү, 80 нче б. (телдән)**

**Укы. Татарчага тәрҗемә ит. Саннарны тап, сораулар куй.**

1. Семь раз отмерь, один раз отрежь. 2. Не имей сто рублей, а имей  сто друзей. 3. Ты ему слово, а он тебе два. 4. Семеро одного не ждут.

1. Җиде кат үлчә, бер кат кис.
2. Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын.
3. Син аңа бер сүз әйтәсең, ә ул сиңа - икене.
4. Җидәү бер кешене көтми.

“Бала” электрон китапханәсеннән Дамир Гарифуллинның “Йә, алар кемнәр икән?” шигырен уку.

# Микс-фриз-груп

1. Музыка куела, укучылар шул музыкага бии-бии әйләнәләр.



2. Музыка туктагач, бер урында басып калалар.

3. Укытучы сорау бирә, укучылар шул сорауның җавабынча берләшәләр.

# “Эш дәфтәре”ндәге биремне үтәү

**63 нче күнегү (язмача)**

**Укы. Саннарны цифрлар белән яз.**

**Биш китап, җиде кыз, унбиш өстәл, егерме сигез укучы, утыз тугызынчы йорт, өч дәрес, алты кеше.**

# Дәреслек белән эш

**104 нче күнегү, 81 нче б. (телдән)**

**Укы. Микъдар һәм тәртип саннарын файдаланып, сорауларга җавап бир.**


1. Син укыган мәктәп ничә катлы? 2. Син укыган сыйныф ничәнче катта урнашкан? 3. Сыйныфта ничә тәрәзә, урындык, өстәл һәм ишек бар? 4. Сыйныфта ничә кыз һәм малай укый? 5. Әти-әниеңә ничә яшь? 6. Энеңә яки сеңлеңә ничә яшь? 7. Абыеңа яки апаңа ничә яшь? 8. Үзеңә ничә яшь?

# “Эш дәфтәре” ндәге биремне үтәү.

**71 нче күнегү (телдән һәм язмача)**
**Сүзләрне русча укы, татарчага тәрҗемә ит. Тәртип саннары ясап яз.**

**смор1а, 100л, о5, 100рона, 100янка, 40а, 7я.**

# “Модель Фрейер”




Бер укучы бер битне дүрткә бүлә, почмагын бөкләп куя, аннары фломастер белән билгели. Билгеләгәннән соң дүрт якка: төп билгеләре/өстәмә билгеләре/мисаллар/сан сүз төркеменә туры килми торган сүзләр дип язалар. Уртага “Сан” дип языла.



**– Бүгенге дәрескә нинди уку мәсьәләсе куйган идек? Без нәрсәне өйрәнергә тиеш идек?**

**- Без дәрестә ниләр эшләдек?**





# Өй эше:

1) 111 нче күнегү, 84 нче б. (мәҗбүри)

2) 113 нче күнегү, 85 нче б. Ребуслы җөмләләрне дөрес итеп укы (ярымиҗади)

3) 110 нчы күнегү, 84 нче б. “Саннар тормышта ни өчен кирәк?” дигән темага кечкенә хикәя яз (иҗади)

# Белемнәрне бәяләү



- дәрес материалын бик яхшы үзләштердем, хәтта иптәшләремә дә булыша алам.



- дәрестә әйбәт эшләдем, материалны аңладым.



- әйбәт эшләдем, ләкин бераз ярдәм дә кирәк.

# Табышмаклар

**Икәү карап тора,**
**Икәү тыңлап тора,**
**Берәү сайрап тора.**

**Колаклар, күзләр, тел.**

**Бер тирәк,**
**Унике ботак,**
**Һәр ботакта дүрт чыпчык,**
**Һәр чыпчыкка җиде яфрак,**
**Һәр яфракның бер ягы кара, бер ягы ак.**

**Ел, айлар, атналар, көн һәм төн.**

**Унике йолдызга бер ай.**

**Айлар һәм ел.**

# Санамышлар

Бер алма,
Ике алма,
Өч алма,
Дүрт алма,
Биш алма,
Алты алма,
Җиде алма,
Сигез алма,
Тугыз алма,
Кызыл алма.





**Үрнәк буенча үзең дә санамыш төзеп әйт.**

# Ял минуты
# Туп ыргытып санау

1. Русча дистәләп 100 гә кадәр саныйбыз.

2. Инглизчә унга кадәр саныйбыз.

3. Татарча уннан бергә кадәр саныйбыз.